РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Чистопольский
муниципальный район
Исполнительный комитет
Большетолкишского сельского поселения

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Чистай муниципаль районы
Зур Талкыш авыл җирлеге
Башкарма комитеты

422967, Чистопольский район с.Большой Толкиш, ул.Пришкольная, д. 2 «А»,
тел. 8(84342) 3-37-38. E-mail Btol.Ctp@tatar.ru

Постановление Карар

2019 елның 24 декабре №10

Чистай муниципаль районының
Олы Талкыш авыл җирлеге гражданнарының
үзара салым акчаларын җыю Тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән, Чистай муниципаль районының «Олы Талкыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Чистай муниципаль районының Олы Талкыш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыеннарында кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатларында (Каратаевка авылы гражданнар җыенының 2019 елның «20» ноябрендәге 1 номерлы карары, Рус Сарсазы авылы гражданнар җыенының 2019 елның «20» ноябрендәге 1 номерлы карары, Кызылъяр авылы гражданнар җыенының 2019 елның 23 ноябрендәге 1 номерлы, Олы Талкыш авылы гражданнар җыенының 2019 елның «24» ноябрендәге 1 номерлы карары ) Чистай муниципаль районы Олы Талкыш авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Чистай муниципаль районының Олы Талкыш авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю буенча тәкъдим ителгән Тәртипне расларга.
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендлары аша игълан итәргә һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында http:/chistopol.tatarstan.ru урнаштырырга.

Олы Талкыш авыл
җирлеге башлыгы Э.Б.Ильин

Чистай муниципаль районы
Олы Талкыш авыл җирлегенең
Башкарма комитеты тарафыннан
2019 елның 24 декабре 10 номерлы
карары белән расланды

Чистай муниципаль районының
Олы Талкыш авыл җирлеге гражданнарының
үзара салым акчаларын җыю Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Чистай муниципаль районының Олы Талкыш авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчалары 2020 елның 10 мартына кадәр Чистай муниципаль районының Олы Талкыш авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарын исәпкә алмаганда,18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан, аларның җыенда катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә карамастан, түләнә.

3. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү кәгазе (хәбәрнамә) бланкы, Чистай муниципаль районы Олы Талкыш авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерү юлы белән яисә имза куеп тапшыру, яки почта элемтәсе аша җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчасын күчерү реквизитлары, бер тапкыр түләнә торган түләү суммасы, тулы күләмдә яисә киметелгән күләмдә, аны түләү срогы күрсәтелергә тиеш.

4. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Чистай муниципаль районының «Олы Талкыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең шәхси счетына керә.

5. Гражданнар тарафыннан түләү физик затлар кушуы буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешмалар аша, почта күчерүләре (исәп-хисап оешмаларын) Чистай муниципаль районы Олы Талкыш авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша, яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша (сылтама буенча), акча күчерү юлы белән башкарыла https://uslugi.tatarstan.ru/.

6. Түләү фактын раслау булып килү касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

7. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

ТР Чистай муниципаль
районының
Олы Талкыш авыл җирлеге
гражданнарының үзара салым
акчаларын җыю Тәртибенә
кушымта

ТР Чистай муниципаль районы ____________ авыл җирлеге муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым акчаларын бер тапкыр түләү турында

ХӘБӘР (ХӘБӘРНАМӘ) № _______________

Түләүченең Ф. И. атасының исеме
____________________________________________________________________________

Адрес: _______________________________________________________________

__________________________________________________________________ нигезендә

Сезгә, түбәндәге реквизитлар буенча: ________________ срогына кадәр, __________ суммада, чараларны тормышка ашыру өчен бер тапкыр түләү түләргә кирәк.

түбәндәге реквизитлар буенча:___________________________________________________

Алучы Банк БИК _______________________________________

Сч. № __________________________________

Алучы Сч. № __________________________________________

ИНН ___________________________________________

КПП ___________________________________________

КБК _______________ ОКАТО ___________________

Түләү билгеләү
____________________________________________________________________________

Җитәкче __________________ _________________________________________

М.П. (имза) (тулы имза)

- - - - - - - - - - - - - - - - - кисү өчен - - - - - - - - - - - - - - -

хәбәр (хәбәрнамә) № _____

_________________ сум күләмендә

Түләүченең  Ф. И. атасының исеме ____________________________________________

Адрес: ______________________________________________________________________________

Алды  «__» ________________ 20__ ел.   ________________________________________

(түләүче имзасы)

Искәрмә. Корешокның өзелгән өлеше _____________ авыл җирлеге Башкарма комитетында тутырыла һәм кала.